**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09,
email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.08.2024 **Чирмешән авылы** № 295

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген җир кишәрлегендә урнашкан биналар милекчесе тарафыннан милеккә яисә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 30 октябрендәге 443 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген җир кишәрлегендә урнашкан биналар милекчесе тарафыннан милеккә яисә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 октябрендәге 443 номерлы карары белән расланган 2.9 пунктының 8 пунктчасын (23.06.2021 №251, 29.08.2022 №295 үзгәрешләр белән) яңа редакциядә бәян итәргә: «8) җир кишәрлеге бирү турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, моңа шундый җир кишәрлегендә урнашкан бинаның, корылманың, андагы биналарның, тәгәлләнмәгән төзелеш объектының милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе җир кишәрлеге бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар керми;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов